Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районында социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен 2018 елга наемга алу өчен түләү күләмен исәплөү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында " 2022 елның 11 февралендәге 52 номерлы карары

Россия Федерациясе Торак кодексының 156, 158 статьялары, Россия Төзелеш министрлыгының «социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен торак урыннардан файдалану өчен түләү күләмен билгеләүнең методик күрсәтмәләрен раслау турында» 2016 елның 27 сентябрендәге 668 /пр номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 11 маендагы 94 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районындагы муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучыларга 2018 елга наем өчен түләү күләмен исәплөү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2018 елга» саннарын төшереп калдырырга;

1 пунктта «2018 елга» саннарын төшереп калдырырга;

Кушымта исемендә «2018 елга» санын төшереп калдырырга;

кушымтада бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

(Нб= СРс* 0,001 формуласы буенча исәплəп, монда, СРС - муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм торак урыннары наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыны урнашкан Татарстан Республикасында икенчел торак базарында фатирларның 1 кв.метр гомуми мәйданының уртача бәясе.);».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары А.М. Хәсәновка йөкләргә.

Җитәкче А. А. Тугушев